ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.08.2025 г.Лениногорск № 694

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 18 ноябрендәге 1080 номерлы карары белән расланган гражданнарны милеккә җир кишәрлекләрен бушлай бирү хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына өстәмә кертү турында

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы 15 өлешенең 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 18 ноябрендәге 1080 номерлы карары белән расланган гражданнарны милеккә җир кишәрлекләрен бушлай бирү хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге өстәмәне кертергә:

2.8.2 пунктның 5 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Гражданнарга аларны исемлекләрдән төшереп калдыру һәм аларга җир кишәрлеге бирүдән баш тарту турында хәбәр итү җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән алып 7 көннән дә соңга калмыйча тапшырылуы турында хәбәр итеlә торган заказлы хат белән йә аларга имза салып хәбәр итү юлы белән тапшырыла.».

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче М.Н. Гирфанов

Галимова Л.М.
5-44-72